**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 17 август № 569

г. Казань

Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия турында

Татарстан Республикасының яшьләр хокук саклау хәрәкәтен үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендияне (алга таба – Стипендия) гамәлгә куярга.

2. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

Стипендия турында нигезләмәне;

Стипендия бирү комиссиясе составын.

3. Стипендия бирү буенча чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасы акчасы исәбеннән башкарыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 17 август, 569 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге махсус еллык стипендия (алга таба – Стипендия) яшьләр арасында хокук бозулар профилактикасы һәм җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү эшчәнлегендә актив катнашучы Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары студентларына һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентларына (алга таба – Белем бирү оешмасы) билгеләнә.

2. 9 Стипендия гамәлгә куела, шул исәптән:

3 Стипендия – дәүләт һәм дәүләт аккредитацияләре булган дәүләтнеке булмаган югары белемнең белем бирү оешмалары студентлары өчен;

6 Стипендия – Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен.

3. Стипендиянең түбәндәге күләмнәре билгеләнә:

дәүләт һәм дәүләт аккредитацияләре булган дәүләтнеке булмаган югары белемнең белем бирү оешмалары студентлары өчен – ай саен 3 300 сум;

Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен – ай саен 2 050 сум.

4. Стипендия составын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия бирү комиссиясе (алга таба – Комиссия) карары нигезендә бер уку елының 9 ае дәвамында (сентябрьдән майга кадәр) түләнә.

5. Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен җәмәгать тәртибен саклау буенча формированиедә катнашучы Белем бирү оешмасы студентлары укуның икенче елыннан, яшьләр арасында социаль тискәре күренешләр профилактикасын гамәлгә ашыруда, хокук тәртибен саклауда, җәмәгатьчелек иминлеген тәэмин итүдә, яшьләр хокук саклау хәрәкәтен үстерүдә уңышлары булган дәүләт һәм дәүләт аккредитацияләре булган дәүләтнеке булмаган югары белемнең белем бирү оешмалары студентлары өчен укуның өченче елыннан Стипендия алырга теләк белдерә ала.

6. Стипендия бирүдә катнашу өчен кандидатлар чыгару ел саен 1 октябрьдән алып 1 ноябрьгә кадәр түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

Белем бирү оешмасының җәмәгать тәртибен саклау буенча формирование җитәкчесе яки кураторы;

«Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләренең территориаль үзәге;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә эчке эшләр органы.

7. Стипендия бирү өчен кандидатларны Комиссия карап тикшерүе өчен документлар исемлеге:

Белем бирү оешмасының җәмәгать тәртибен саклау буенча формирование җитәкчесе яки кураторы тәкъдиме;

Белем бирү оешмасының җәмәгать тәртибен саклау буенча формирование кураторы таныклаган уку урыныннан сыйфатлама һәм кандидатның җәмәгать тәртибен саклау буенча формированиедә эше турында белешмәләр;

«Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләренең территориаль үзәге һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә эчке эшләр органы җитәкчеләреннән кандидат турында бәяләмә;

җәмәгать тәртибен тәэмин итүгә һәм хокук бозулар профилактикасына үз өлешен керткән кандидатның яшьләр хокук саклау хәрәкәтен үстерүдәге уңышларын бәяли торган дипломнар, грамоталар, рәхмәт хатлары, массакүләм мәгълүмат чараларындагы материаллар күчермәләре;

паспорт, ИНН таныклыгы, СНИЛС күчермәләре.

8. Документларны тапшыру адресы: Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Казан шәһәре, Петербург ур., 12 йорт.

9. Стипендия алуга документлар тапшыру ел саен 1 ноябрьгә кадәр башкарыла.

10. Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән документлар белән кандидатлар исемлеген 5 ноябрьгә кадәр Комиссия секретары гомумиләштерә һәм Комиссия рәистәшләренә һәм әгъзаларына җибәрә.

11. Махсус стипендияләрне бирүгә кандидатларны карап тикшерү Комиссия тарафыннан 10 ноябрьдән дә соңга калмыйча утырышта Комиссия әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашында үзләре билгеләгән методика нигезендә Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән башкарыла.

12. Утырышны Комиссия рәистәшләренең берсе яки Комиссия рәисе урынбасары үткәрә. Тавышлар тигез булганда, рәислек итүче тавышы хәлиткеч була.

13. Стипендия бирү турында Комиссия карары утырыш үткәрелгән көннән соң өч эш көне эчендә беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының стипендия билгеләү турында боерыгы белән раслана.

14. С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия билгеләү вакытына республика, федераль, халыкара статустагы башка исемле стипендияләр һәм (яки) грантлар алучы затларга бирелергә мөмкин.

15. Стипендия түләү Комиссиянең Стипендия бирү турында карары белән түбәндәге айдан соң килә торган айның беренче көненнән туктатыла:

Белем бирү оешмасының укучыны укудан чыгару турында боерыгы басылган;

С.З.Япеев исемендәге стипендиат Белем бирү оешмасының җәмәгать тәртибен саклау буенча формированиедән чыккан;

стипендиатның хокук бозуы очраклары билгеле булган.

16. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында каралган фактлары билгеле булган очракларда, Комиссия әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашында Стипендия түләүне туктатуны карап тикшерү турында Комиссия утырышы үткәрелә. Карар Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 17 август, 569 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия бирү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры, комиссия рәистәше |
| Хохорин Артём Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры, комиссия рәистәше (килешү буенча) |
| Гарифуллин Рөстәм Марат улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Пивоварова Наталья Дмитриевна | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының өстәмә белем бирү һәм социаль программалар бүлеге башлыгы, комиссиянең җаваплы секретары |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Гарифуллина Илсөяр Хәләлетдин кызы | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау республика комиссиясе җаваплы секретары |
| Җәләлева Анфиса Григорьевна | «Татарстан Республикасы урта һөнәри белемнең мәгариф учреждениеләре директорлары советы» коммерцияле булмаган партнерлык рәисе, «Казан педагогика көллияте» урта һөнәри белемнең дәүләт автоном мәгариф учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Искәндәров Элькин Эльманович | «Татарстан Республикасы студентлары лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы президенты (килешү буенча) |
| Осипова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция участок вәкилләре һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләр эшчәнлеген оештыру идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Рыков Андрей Львович | ««Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләренең республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Сулима Лариса Олеговна | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Шакирова Гузәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы. |